КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 сентябрь г.Казань № 882

Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

2022 елга – койко-көнгә 617,85 сум күләмендә;

2023 елга – койко-көнгә 619,38 сум күләмендә;

2024 елга – койко-көнгә 620,96 сум күләмендә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентларын;

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар санын.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 877 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль рәвештә йөрү яки әйләнә-тирәдәге шартларда ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 877 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 август, 716 нчы карары.

4. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 18 сентябрь, 882 нче
карары белән расланды

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы мәгънәсенә йогынты ясый торган башка факторларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентлары

| Исеме муниципаль берәмлек | Корректировкалау (төзәтү) коэффициенты күләме | | |
|---|---|---|---|
| | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Азнакай муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Әлмәт муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Алабуга муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Зәй муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 1,798947 | 1,799015 | 1,799114 |
| Лениногорск муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Чистай муниципаль районы | 1,735980 | 1,736203 | 1,736462 |
| Яр Чаллы шәһәре | 1,087731 | 1,088494 | 1,089320 |
| Казан шәһәре | 1,087864 | 1,088649 | 1,089486 |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 18 сентябрь, 882 нче
карары белән расланды

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булучы затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар саны

| Муниципаль берәмлек исеме | Койкалар саны |
|---|---|
| Азнакай муниципаль районы | 10 |
| Әлмәт муниципаль районы | 10 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 10 |
| Алабуга муниципаль районы | 10 |
| Зәй муниципаль районы | 10 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 10 |
| Лениногорск муниципаль районы | 10 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 10 |
| Чистай муниципаль районы | 10 |
| Яр Чаллы шәһәре | 20 |
| Казан шәһәре | 40 |

_______________________________